# КАРАР

28 ноябрь 2019 ел №4

*Гражданнарнын үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча* Кукмара муниципаль районынын Битлянгур авылы Түбән Өскебаш авылы җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында.

"*Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары* турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнын 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 27.11.2019 һәм 28.12.2019 елда Югарыдагы сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Кукмара муниципаль районынын Битлянгур авылы, Түбән Өскебаш авылы *җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем* инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә һәтле 4 һәм аннан артык балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, ялгыз әниләрдән, 85 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2020 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә риза булырсызмы?

- Битлянгур авылының Комсомольская һәм Гагарин урамы буенча юлга вак таш түшәү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; юл салу;
- Битлянгур авылындагы юлларны кардан чистарту;
- Пожар сүндерү машинасына запчастьләр алу;
- Бүә территориясендәге машина юлын ремонтлау;
- Битлянгур авылындагы артезиан скважиналары өчен насослар алу;
- Битлянгур авылындагы чишмәне ремонтлау;
- Битлянгур вылындагы балалар мәйданчыгыга материаллар сатып алып койма тоту;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган ,җыенда катнашучылар исемлегенә, 243 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның саны 134.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар югарыдагыча бүленде:

"Әйе" позициясе өчен 134 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен гражданнар җыенында *0* катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Түбән Өскебаш авыл җирлегенең Битлянгур авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.
2. Сорау буенча карарны танырга: «2020 елда үзара салым кертүгә Кукмара муниципаль районының Битлянгур авылы, Түбән Өскебаш авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә һәтле 4 һәм аннан артык балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, ялгыз әниләрдән, 85 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешеп торасызмы:

- Битлянгур авылының Комсомольская һәм Гагарин урамы буенча юлга вак таш түшәү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; юл салу;
- Битлянгур авылындагы юлларны кардан чистарту;
-Пожар сүндерү машинасына запчастьләр алу;
-Бүә территориясендәге машина юлын ремонтлау;
- Битлянгур авылындагы артезиан скважиналары өчен насослар алу;
-Битлянгур авылындагы чишмәне ремонтлау;
-Битлянгур вылындагы балалар мәйданчыгыга материаллар сатып алып койма тоту;

;

«РИЗА» «КАРШЫ»

-кабул ителде.

3.“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтын урнаштыру юлы белән гражданнар җыенының нәтиҗәсен бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында Югарыдагы адрес буенча бастырырга: www.pravo.tatarstan.ru,.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Авыл җирелеге башлыгы Н.М.Мөхәммәтҗанов